КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 30 октябрь г.Казань № 971

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында энергия саклау һәм энергетика нәтиҗәлелеген күтәрү» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 4 декабрь, 954 нче карары белән расланган «Татарстан Республикасында энергия саклау һәм энергетика нәтиҗәлелеген күтәрү» дәүләт программасына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында энергия саклау һәм энергетика нәтиҗәлелеген күтәрү» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 4 декабрь, 954 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 13 май, 317 нче; 2014 ел, 24 сентябрь, 670 нче; 2014 ел, 12 ноябрь, 861 нче; 2015 ел, 26 март, 189 нчы; 2016 ел, 2 декабрь, 889 нчы; 2018 ел, 28 май, 404 нче; 2018 ел, 10 сентябрь, 765 нче; 2019 ел, 22 гыйнвар, 32 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган «Татарстан Республикасында энергия саклау һәм энергетика нәтиҗәлелеген күтәрү» дәүләт программасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Программа паспортында

«Программаны тормышка ашыру вакытлары һәм этаплары» юлында «2014 – 2021 елларга» сүзләрен «2014 – 2024 елларга» сүзләренә алмаштырырга;

«Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, финанслау күләмнәре» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, финанслау | Программаны финанслауның гомуми күләме 36 525 411,3 мең сум тәшкил итә, шул исәптән җәлеп итәргә планлаштырыла торган федераль бюджет акчасы исәбеннән – 266 582,0 мең сум, Татарстан Республикасы бюджеты акчасы |

<table>
<tr>
<td>күләмнәре</td>
<td>исәбеннән – 2 437 305,7 мең сум, бюджеттан тыш чыганаклардан – 33 821 523,6 мең сум.<br>(мең сум)
<table>
<tr><th>Ел</th><th>Барлыгы</th><th>Татарстан Республикасы бюджеты акчасы</th><th>федераль бюджет акчасы</th><th>бюджеттан тыш чыганаклар акчасы</th></tr>
<tr><td>2014</td><td>4 813 302,2</td><td>1 273 412,8</td><td>266 582,0</td><td>3 273 307,4</td></tr>
<tr><td>2015</td><td>4 666 847,5</td><td>1 136 565,5</td><td>0,0</td><td>3 530 282,0</td></tr>
<tr><td>2016</td><td>3 891 326,0</td><td>0,0</td><td>0,0</td><td>3 891 326,0</td></tr>
<tr><td>2017</td><td>4 329 307,4</td><td>8 607,4</td><td>0,0</td><td>4 320 700,0</td></tr>
<tr><td>2018</td><td>4 760 635,4</td><td>4 735,4</td><td>0,0</td><td>4 755 900,0</td></tr>
<tr><td>2019</td><td>5 253 196,6</td><td>5 596,6</td><td>0,0</td><td>5 247 600,0</td></tr>
<tr><td>2020</td><td>1 800 088,2</td><td>8 388,0</td><td>0,0</td><td>1 791 700,2</td></tr>
<tr><td>2021</td><td>1 824 991,1</td><td>0,0</td><td>0,0</td><td>1 824 991,1</td></tr>
<tr><td>2022</td><td>1 541 575,0</td><td>0,0</td><td>0,0</td><td>1 541 575,1</td></tr>
<tr><td>2023</td><td>2 545 427,8</td><td>0,0</td><td>0,0</td><td>2 545 427,9</td></tr>
<tr><td>2024</td><td>1 098 714,1</td><td>0,0</td><td>0,0</td><td>1 098 714,1</td></tr>
<tr><td>Барлыгы</td><td>36 525 411,3</td><td>2 437 305,7</td><td>266 582,0</td><td>33 821 523,6</td></tr>
</table>
Программа юнәлешләре буенча Татарстан Республикасы бюджетыннан бүлеп бирелә торган акча суммалары чираттагы финанс елына Татарстан Республикасы бюджеты турындагы Татарстан Республикасы законы нигезендә ел саен тәгаенләнәчәк.<br>Программаны федераль бюджет акчасы исәбеннән тормышка ашыруны ресурслар белән тәэмин итү күләме Татарстан Республикасының чыгым йөкләмәләрен финанслашу шартларында Россия Федерациясенең Энергетика министрлыгы һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты белән ел саен төзелә торган килешүләр нигезендә билгеләнәчәк»;</td>
</tr>
</table>

«Еллар буенча бүлеп, Программаның максатларын һәм бурычларын тормышка ашыру буенча көтелә торган соңгы нәтиҗәләр (нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары) һәм Программаның бюджет нәтиҗәлелеге күрсәткечләре» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Еллар буенча бүлеп, Программаның максатларын һәм бурычларын тормышка ашыру буенча | 2024 елга тулаем төбәк продуктының (алга таба – ТРП) энергия сыйдырышлылыгын чагыштырмача 2007 ел дәрәҗәсенә карата (2024 елга индикатор мәгънәсе 20,26 ш.я.т./млн. сум тәшкил итәчәк) Программаны тормышка ашыру чаралары исәбеннән 24,8 процентка киметү»; |

| | |
|---|---|
| көтелә торган соңгы нәтиҗәләр (нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары) һәм Программаның бюджет нәтиҗәлелеге күрсәткечләре | |

Программаның II бүлегендә:
6 нчы таблицаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6 нчы таблица


2024 елга кадәрге чорга ТРПның энергия сыйдырышлылыгы индикаторының максатчан мәгънәләре

(ш.я.т./млн.сум)


| Индикатор исеме | 2007 ел | 2013 ел | 2014 ел | 2015 ел | 2016 ел | 2017 ел | 2018 ел | 2019 ел | 2020 ел | 2021 ел | 2022 ел | 2023 ел | 2024 ел |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 2007 ел бәяләрендә ТРПның энергия сыйдырышлылыгы | 27,41 | 21,53 | 21,37 | 21,20 | 21,04 | 20,88 | 20,94 | 20,92 | 20,86 | 20,80 | 20,74 | 20,68 | 20,62»; |

6 нчы таблицадан соң килә торган үз көчен югалткан дип танырга;
7 нче таблица үз көчен югалткан дип танырга;
Программаның III бүлегендә:
икенче абзацта «26,1» һәм «33 537 315,7» саннарын тиешенчә «26,1» һәм «36 525 411,3» саннарына алмаштырырга;


15 – 17 рәисемнәрне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:



15 рәс. 2007 ел бәяләрендә ТРП динамикасы һәм үсеш фаразы (млрд.сум)




16 рәс. Беренчел энергия чыганакларын куллану динамикасы һәм фаразлары (ш.я.млн.т.)





17 рәс. ТРПның энергия сыйдырышлылыгы динамикасы һәм фаразы (ш.я.т./млн. сум)»;

17 рәсемнән соң килә торган «33 537 315,7», «2 428 917,7» һәм «30 841 815,4» саннарын тиешенчә «36 525 411,3», «2 437 305,7» һәм «33 821 523,6» саннарына алмаштырырга;

Программаның IV бүлегендә:

18 рәсемне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:



18 рәс. Программаны тормышка ашыру чаралары белән идарә итүне һәм аларның үтәлешен контрольдә тотуны оештыру системасы;

Программа теркәлгән 1 нче кушымтаны (карарга теркәлә) яңа редакциядә бәян итәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин